КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 май г.Казань № 375

2019 елда муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2019 елда муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 3 май, 375 нче
карары белән расланды

2019 елда муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип 2019 елда муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү (алга таба – муниципаль хезмәткәрләрнең мәҗбүри дәүләт иминияте, башка бюджетара трансфертлар) максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар муниципаль хезмәткәрләрнең мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм Татарстан Республикасының шәһәр округлары бюджетларына (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бирелә.

3. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

4. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2019 елда Министрлыкка ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

5. Муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = (DO_i + OKC_i) \times P,$$

монда:

$S_i$ – i муниципаль берәмлеге өчен 1 елга исәпләгәндә муниципаль хезмәткәрләрнең мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыруга башка бюджетара трансфертлар күләме, мең сум;

$DO_i$ – i муниципаль берәмлегендә расланган штат расписаниеләре нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең айлык фондына тигез булган акча суммасы, мең сум;

$OKC_i$ – i муниципаль берәмлегендә расланган штат расписаниеләре нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең айлык фондыннан дүрт процентка тигез булган акча суммасы, мең сум;

Р – һәрбер иминиятләштерелгән зат өчен түләнә торган иминият премиясе күләмен исәпләп чыгару өчен мәгънәсе 0,0875 кә тигез булган коэффициент.

6. Муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта мәҗбүри дәүләт иминиятен бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән шартлар нигезендә гамәлгә ашыру турындагы муниципаль норматив хокукый актның булуы башка бюджетара трансфертлар бирү өчен шарт булып тора.

7. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль берәмлекләр башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы заявканы (алга таба – заявка) Министрлык тарафыннан билгеләнгән форма буенча Министрлыкка кертә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы карар заявка кергән көннән биш эш көне эчендә Министрлык тарафыннан кабул ителә.

9. Заявка бу Тәртипнең 7 нче пунктына туры килмәгән очракта, шулай ук муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлмәгән очракта, Министрлык гаризаны кабул итми һәм заявка кергән көннән эш көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә бу турыда, заявканы кабул итмәү сәбәпләрен күрсәтеп, башка бюджетара трансферт алучыга хәбәр итә.

Муниципаль берәмлек заявканы кабул итмәү турында хәбәрнамә алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бу Тәртип белән билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән кабат гариза бирергә хокуклы.

10. Башка бюджетара трансфертлар башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Министрлык һәм муниципаль берәмлек арасында Министрлык тарафыннан расланган форма буенча төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә бирелә.

11. Министрлык килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә башка бюджетара трансфертларны Федераль казначылыкның территориаль органнарында ачылган муниципаль берәмлекләр бюджетларының шәхси счетларына күчерә.

12. Муниципаль берәмлекләр башка бюджетара трансфертларны файдалану турындагы хисапларны Министрлыкка килешү белән каралган форма һәм тәртип нигезендә кертә.

13. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы һәм аның вазыйфаи затлары кертелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмау өчен законнар нигезендә җавап бирә.

14. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы килешү һәм бу Тәртип белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

15. Файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар муниципаль хезмәткәрләрнең мәҗбүри дәүләт иминияте турындагы муниципаль контракт төзелгән көннән 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

16. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган акча күләмендә бәхәссез түләтелә яки башка бюджетара трансфертлар бирү туктатыла.

17. Әгәр дә башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәсә, әлеге акча, Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы бюджеты керемена Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

2019 елда муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә
кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең
җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең
сәламәтлегенә зыян килгән очракта мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыру
шартлары

1. Муниципаль хезмәткәрләрнең тормышы һәм сәламәтлеге дәүләт тарафыннан мәҗбүри иминиятләштерелергә тиеш.

2. Мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминиятләштерүчеләр – муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәте үтә торган җирле үзидарә органнары һәм башка муниципаль органнар (алга таба – иминиятләштерүчеләр).

3. Мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминиятләүчеләр (алга таба – иминиятләүчеләр) мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыруга лицензиясе булган иминият оешмалары булырга мөмкин.

4. Иминиятләүчеләрне сайлап алу дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5. Мәҗбүри дәүләт иминияте турындагы шартнамә (алга таба – иминият шартнамәсе) иминиятләштерүче белән иминиятләүче арасында иминиятләштерелгән зат (файда алучы) файдасына, тәүлегенә 24 сәгать дәвамында иминият саклавын башкарып, бер календарь елга Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә төзелә.

6. Бу Шартларның 8 нче пунктындагы 1 нче пунктчада күрсәтелгән иминият очраклары өчен иминиятләштерүче тарафыннан иминият шартнамәсендә файда алучылар даирәсе билгеләнә. Иминият шартнамәсендә иминиятләштерүче тарафыннан иминиятләштерелгән затның вафат булган көнендә аның белән теркәлгән никахта яшәгән ире (хатыны), иминиятләштерелгән затның ата-анасы (уллыкка (кызлыкка) алынучылар), иминиятләштерелгән затның бабасы һәм әбисе – әгәр дә аның ата-анасы булмаган шартларда алар аны кимендә өч ел тәрбияләсә һәм караса, иминиятләштерелгән затның үги атасы һәм анасы – әгәр дә алар аны кимендә биш ел тәрбияләсә һәм караса, иминиятләштерелгән затның 18 яше тулмаган яки бу яшьтән зуррак булган (әгәр дә алар 18 яше тулганга кадәр инвалид булсалар), шулай ук теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешләрендәге һәм милек рәвешләрендәге белем бирү оешмаларында укуы тәгәлләнгәнгә (әмма аларга 23 яше

тулганга) кадәр генә укыган балалары, иминиятләштерелгән затның опекага алынган кешеләре файда алучылар сыйфатында мәҗбүри тәртиптә күрсәтелергә тиеш. Файда алучылар иминият шартнамәсендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан аның иминиятләштерүчесе билгеләгән тәртиптә бирелә торган мәгълүмат нигезендә күрсәтелә. Иминият шартнамәсендә файда алучылар күрсәтелмәгән очракта, иминиятләштерелгән затның граждан законнары белән билгеләнгән тәртиптә мираска хокуклы кешеләре файда алучылар дип танылa.

7. Муниципаль хезмәткәрне төзелгән иминият шартнамәсе гамәленең вакыты чыкканга кадәр муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итү әлеге муниципаль хезмәткәргә карата аның гамәлен муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгән көннән туктатуга китерә. Әлеге нигез буенча муниципаль хезмәткәргә карата иминият шартнамәсенең гамәле вакытыннан алда туктатылган очракта, иминиятләүче әлеге муниципаль хезмәткәрне иминиятләштерүгә бәйле рәвештә түләнгән иминият премиясен иминиятләштерүчегә бу муниципаль хезмәткәргә карата иминият шартнамәсе гамәленең пропорциональ калган вакыты өлешендә бу Шартларның 21 нче пункты белән билгеләнгән тәртиптә кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

8. Иминият очраклары түбәндәгеләр була:

1) иминиятләштерелгән зат муниципаль хезмәт үтү чорында, шулай ук муниципаль хезмәт үткән чорда алынган имгәнүләр, җәрәхәтләр яки авырулар аркасында муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә вафат булу;

2) иминиятләштерелгән затка муниципаль хезмәт үтү чорында, шулай ук муниципаль хезмәт үткән чорда алынган имгәнүләр, җәрәхәтләр яки авырулар аркасында муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә инвалидлык бирү;

3) иминиятләштерелгән зат муниципаль хезмәт үткән чорда имгәнүләр яки җәрәхәтләр алу;

4) эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле инициативасы буенча муниципаль хезмәткәрне үзе биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан һәм медицина бәяләмәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча һәм инвалидлык бирүгә бәйле булмаган рәвештә муниципаль хезмәттән азат итеп, хезмәт шартнамәсен (контрактны) өзү өчен нигез булган авыру белән иминиятләштерелгән затның авыруы.

9. Иминиятләштерелгән затларга (файда алучыларга) түләнә торган иминият суммаларының күләмнәре, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладыннан (алга таба – оклад) чыгып, ул биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы һәм муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тоту окладын тәшкил иткән классны чин өчен айлык өстәмә түләү нигезендә билгеләнә.

Иминият очраклары башланганда иминият суммалары түбәндәге күләмнәрдә түләнә:

1) иминиятләштерелгән зат муниципаль хезмәт үтү чорында, шулай ук муниципаль хезмәт үткән чорда алынган имгәнүләр, җәрәхәтләр яки авырулар аркасында муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә вафат булган очракта – 26,25 оклад;

2) иминиятләштерелгән затка муниципаль хезмәт үтү чорында, шулай ук муниципаль хезмәт үткән чорда алынган имгәнүләр, җәрәхәтләр яки авырулар аркасында муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә инвалидлык бирелгән очракта:

I төркем инвалидына – 17,5 оклад;

II төркем инвалидына – 12,25 оклад;

III төркем инвалидына – 10,5 оклад;

3) иминиятләштерелгән зат муниципаль хезмәт үткән чорда авыр имгәнүләр яки җәрәхәтләр алган очракта – җиде оклад, җиңел имгәнүләр яки җәрәхәтләр алган очракта – 1,75 оклад;

4) эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле инициативасы буенча муниципаль хезмәткәрне үзе биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан һәм медицина бәяләмәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча һәм инвалидлык бирүгә бәйле булмаган рәвештә муниципаль хезмәттән азат итеп, хезмәт шартнамәсен (контрактны) өзү өчен нигез булган авыру белән иминиятләштерелгән зат авырган очракта – 8,75 оклад.

10. Әгәр дә муниципаль хезмәт үткән чорда яки муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел үткәнгә кадәр федераль медицина-социаль экспертиза учреждениесендә яңадан тикшерелгәндә иминиятләштерелгән затка инвалидлык төркеме арттырылса, иминият суммасының күләме яңа билгеләнгән инвалидлык төркеме буенча бирелергә тиешле окладлар саны һәм элеккеге инвалидлык төркеме буенча бирелергә тиешле окладлар саны арасындагы аерманы тәшкил иткән суммага арттырыла.

11. Әгәр дә иминият очрагына бәйле рәвештә иминиятләштерелгән затка иминият суммасы түләнгән булса, әмма иминият очрагы башланган көннән бер ел эчендә һәм аңа турыдан-туры бәйле рәвештә сәламәтлеге начарланса яки вафат булса, элегрәк түләнгән иминият суммасын тотып калып, өстәмә иминият акчасы (иминият суммалары) түләү гамәлгә ашырыла.

12. Һәр иминиятләштерелгән зат өчен түләнә торган иминият премиясенең күләме иминият шартнамәсе белән билгеләнә һәм иминиятләштерелгән затның иминият шартнамәсе төзү вакытына билгеләнгән окладыннан 8,75 проценттан арттырыла алмый.

13. Иминиятләүче түбәндәге иминият очрагы булганда мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминият суммасын түләүдән азат ителә:

1) иминиятләштерелгән зат тарафыннан суд белән билгеләнгән тәртиптә иҗтимагый куркыныч дип танылган гамәл кылыну аркасында булганда;

2) иминиятләштерелгән затның суд белән билгеләнгән алкогольле, наркотиклы яки токсинлы исереклеге белән турыдан-туры бәйләнеше булганда;

3) иминиятләштерелгән затның суд белән расланган үз сәламәтлегенә аңлы рәвештә зыян китерүе яки иминиятләштерелгән затның үз-үзенә кул салуы аркасында булганда.

14. Иминиятләүче, әгәр дә иминиятләштерелгән затның вафат булуы үз-үзенә кул салуга китерү нәтиҗәсе буларак суд белән расланса, иминият суммасын түләүдән азат ителми.

15. Иминият суммасын түләүдән баш тарту турындагы карар иминиятләүче тарафыннан кабул ителә һәм ул, әлеге баш тарту сәбәпләренең мәҗбүри мотивлаштырылган нигезләвен күрсәтеп, иминиятләштерелгән затка (файда алучыга) һәм иминиятләштерүчегә иминият суммасын түләүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вакыт эчендә язма рәвештә хәбәр ителә.

16. Иминият түләүләрен гамәлгә ашыру иминиятләүче тарафыннан иминиятләштерелгән затның (файда алучының) гаризасы һәм иминиятләштерүче тарафыннан кертелгән иминият очрагы башлануын раслый торган документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

17. Иминият түләүләрен гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге, аларны бирү һәм карау тәртибе иминият шартнамәсе белән билгеләнә.

18. Иминият суммаларын түләү иминиятләштерелгән затларга иминият шартнамәләренең башка төрләре буенча бирелергә тиешле суммаларга бәйсез рәвештә башкарыла.

19. Иминият суммалары иминиятләүче тарафыннан иминиятләштерелгән затларга (файда алучыларга) иминият шартнамәсендә билгеләнгән ысул ярдәмендә бирелергә тиешле суммаларны сумнарда күчерү юлы белән түләнә.

20. Иминият суммаларын түләү иминиятләүче тарафыннан әлеге түләү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар алынган көннән 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

21. Иминият шартнамәсе гамәлдә булган вакыт эчендә иминиятләштерелгән затлар окладларының күләмнәре, шулай ук аларның саннары үзгәрсә, әлеге вакыйгаларга бәйле рәвештә алынып бетмәгән яки артыграк алынган иминият кертемнәре суммасы өстәп түләнергә яки кире кайтарылырга тиеш. Иминият шартнамәсе төзегән якларның килешүе буенча әлеге суммалар иминият шартнамәсе гамәленең чираттагы чоры өчен иминият кертемнәре күләмнәрен билгеләгәндә исәпкә алынырга мөмкин.

22. Иминиятләштерүче тарафыннан иминият кертемнәрен кертү эзлеклелеге иминият шартнамәсе белән билгеләнә.